# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Төркәш авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**13 ноябрь, 2025 ел** **№3**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан (курсантлардан), I төркем инвалидларыннан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2026 елда үзара салымны 1200 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктыртуны ясау;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас

объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- тротуарларны төзү, ремонтлау;
- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;
- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүме.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А.Котдусов